РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ГОРОДА НУРЛАТ
НУРЛАТСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫНЫҢ
НУРЛАТ ШӘҺӘРЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

---

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

26.12.2020 № 38

2021 елның I яртыеллыгында Нурлат муниципаль районы Нурлат шәһәре халкына һәм башка кулланучыларга күрсәтелә торган торак-коммуналь хезмәтләргә тарифларны раслау турында

«Коммуналь комплекс оешмалары тарифларын җайга салу нигезләре турында» 2004 елның 30 декабрендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Коммуналь комплекс оешмалары эшчәнлеге өлкәсендә тарифлар, өстәмәләр һәм чик индекслар бәяләрен билгеләү һәм җайга салу нигезләре турында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2008 елның 14 июлендәге 520 номерлы карары һәм «Коммуналь хезмәт күрсәтүләр өчен гражданнарның түләү күләмен үзгәртүнең иң чик индексларын формалаштыру нигезләрен раслау турында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2009 елның 28 августындагы 708 номерлы карары нигезендә

КАРАР БИРӘМ:

1. Түбәндәгеләрне расларга һәм 2021 елның 1 гыйнварыннан гамәлгә кертергә:

- социаль наем шартнамәләре һәм муниципаль торак фондының торак урыннарына наем шартнамәләре буенча һәм күпфатирлы торак йорт белән идарә итү ысулын сайлау турында карар кабул итмәгән торак урыннар милекчеләре өчен торак хезмәтләре өчен түләү күләме (1 нче кушымта);

- Нурлат шәһәре буенча муниципаль торак фондының торак урыннарына социаль наем шартнамәләре буенча торак урыннар яллаучыларга торак урын яллаган өчен түләү күләме (2 нче кушымта);

2. Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең «Нурлат муниципаль районының 2020 елның II яртыеллыгында халыкка һәм башка кулланучыларга тапшырыла торган торак-коммуналь хезмәтләргә тарифларны раслау турында» 2020 елның 30 июлендәге 23 номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге карарны массакүләм мәгълүмат чараларында, шул исәптән Нурлат муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында (www.nurlat@tatar.ru) бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Татарстан Республикасы
Нурлат муниципаль районы
Нурлат шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесе Ф.Ю. Терентьев

Нурлат муниципаль районы Нурлат шәһәре Башкарма комитетының 26.12.2020 ел, №38 карарына 1 нче кушымта

Социаль наем шартнамәләре һәм муниципаль торак фондының торак урыннарына наем шартнамәләре буенча һәм күпфатирлы торак йорт белән идарә итү ысулын сайлау турында карар кабул итмәгән торак урыннар милекчеләре өчен торак хезмәтләре тарифлары

| *Хезмәтнең исеме* | *Түләү алына торган үлчәү берәмлеге* | *Хезмәт берәмлеге өчен тариф (сумнарда)* |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| Коммуналь түләүләр буенча Бердәм исәп-хисап үзәге хезмәтләре белән торак фонды белән идарә итү | Аена торак бинаның гомуми мәйданы кв.м | 2,97 |
| Коммуналь түләүләр буенча Бердәм исәп-хисап үзәге хезмәтләреннән башка торак фонды белән идарә итү | Аена торак бинаның гомуми мәйданы кв.м | 2,83 |
| Йорт яны территориясен җыештыру һәм чистарту | Аена торак бинаның гомуми мәйданы кв.м | 3,02 |
| Торак фондын агымдагы ремонтлау һәм йорт яны территориясен төзекләндерү | Аена торак бинаның гомуми мәйданы кв.м | 2,13 |
| Йорт эчендәге суүткәргеч-канализация челтәрләренә һәм гомумйорт исәпкә алу приборлары куелган санитар-техник җиһазларга техник хезмәт күрсәтү һәм ремонтлау | Аена торак бинаның гомуми мәйданы кв.м | 1,39 |
| шул исәптән гомумйорт исәпләү приборларына хезмәт күрсәтү | Аена торак бинаның гомуми мәйданы кв.м | 0,14 |
| Йорт эчендәге суүткәргеч-канализация челтәрләренә һәм гомумйорт исәпкә алу приборларыннан башка санитар-техник җиһазларга техник хезмәт күрсәтү һәм ремонтлау | Аена торак бинаның гомуми мәйданы кв.м | 1,25 |
| Җылылык энергиясен исәпкә алу буенча гомумйорт үзәге булган үзәк җылылык челтәрләренә техник хезмәт күрсәтү һәм ремонтлау | Аена торак бинаның гомуми мәйданы кв.м | 1,46 |
| шул исәптән җылылык энергиясен исәпкә алу буенча гомумйорт үзәкләренә хезмәт күрсәтү | Аена торак бинаның гомуми мәйданы кв.м | 0,53 |
| Җылылык энергиясен исәпкә алу буенча гомумйорт төененнән башка үзәк җылылык челтәрләренә техник хезмәт күрсәтү һәм ремонтлау | Аена торак бинаның гомуми мәйданы кв.м | 0,93 |
| Агымдагы ремонт һәм йорт эчендәге газ белән тәэмин итү челтәрләрен карап тоту | Аена торак бинаның гомуми мәйданы кв.м | 0,60 |
| Электр белән тәэмин итүнең йорт эчендәге челтәрләрен агымдагы ремонтлау һәм карап тоту | Аена торак бинаның гомуми мәйданы кв.м | 0,95 |

Нурлат муниципаль районы Нурлат шәһәре Башкарма комитетының 26.12.2020 ел, №38 карарына 1 нче кушымта

Муниципаль торак фондының торак урыннарына социаль наем шартнамәләре буенча торак урыннарны наемга алучылар өчен тариф

| *Хезмәтнең исеме* | *Түләү алына торган үлчәү берәмлеге* | *Хезмәт берәмлеге өчен тариф (сумнарда)* |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| Торак урынны наемга алу | Аена торак бинаның гомуми мәйданы кв.м | 7,94 |